ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО АРХИВНОМУ ДЕЛУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ**

27.10.2017 г. Казань № 136-од

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының 14.10.2016 № 091-од боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты каршындагы Иҗтимагый совет турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы иҗтимагый совет турында» 18.11.2010 № 906 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының 14.10.2016 № 091-од боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты каршындагы Иҗтимагый совет турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә, аны яңа кушып бирелүче редакциясендә бәян итәргә.
2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Рәис И.Х. Әюпова

Татарстан Республикасының
Архив эше буенча дәүләт комитетының
14.10.2016 № 091-од (Татарстан
Республикасының Архив эше буенча
дәүләт комитетының 27.10.2017
№ 136-од боерыгы редакциясендә)
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасының
Архив эше буенча дәүләт комитеты каршындагы
Иҗтимагый совет турында
нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты каршындагы Иҗтимагый совет (алга таба – Иҗтимагый совет) архив эше өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы, дәүләт сәясәтен формалаштырганда һәм гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасында гражданнар ирекләрен һәм хокукларын, иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дәүләтнеке булмаган коммерциячел булмаган бүтән оешмаларның хокукларын гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләрне караучы, шулай ук әлеге Нигезләмә белән каралган бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты (алга таба – ТР Дәүләт архив комитеты) каршындагы киңәшү органы була.

1.2. Иҗтимагый совет составы һәм саны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты һәм ведомствосы каршындагы иҗтимагый совет төзү тәртибе нигезендә ТР Дәүләт архив комитеты боерыгы белән раслана.

1.3. Үз эшчәнлегендә Иҗтимагый совет Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.4. Иҗтимагый совет карарлары тәкъдим итү характерында була.

1.5. Иҗтимагый совет үз эшчәнлеген иҗтимагый башлангычларда гамәлгә ашыра.

1.6. Иҗтимагый совет эше ирекле нигезгә, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә ачыклык һәм партнерлык принципларына корыла.

1.7. Иҗтимагый совет үз эшен граждан җәмгыяте институтларының, дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының, массакүләм мәгълүмат чараларының вәкилләренең үзара кызыксынуы нигезендә гамәлгә ашыра.

## 2. Иҗтимагый совет эшчәнлеге максатлары һәм бурычлары

2.1. Иҗтимагый совет эшчәнлегенең төп максатлары түбәндәгеләр була:

архив эше өлкәсендә дәүләт сәясәтен формалаштырганда һәм гамәлгә ашырганда гражданнар ихтыяҗларын һәм мәнфәгатьләрен исәпкә алу, гражданнар хокукларын һәм ирекләрен, иҗтимагый берләшмәләр һәм дәүләтнеке булмаган коммерциячел булмаган бүтән оешмалар хокукларын яклау;

иҗтимагый, һөнәри һәм иҗат берләшмәләре вәкилләрен архив эшчәнлегенә кагылышлы мәсьәләләр буенча дәүләт сәясәтенең төп юнәлешләрен эшләүгә җәлеп итү, ТР Дәүләт архив комитеты эшчәнлегенең ачыклык һәм хәбәрдарлык принцибын тормышка ашыру;

«Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба – «ТР ДА» ДБУ) тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре сыйфатын иҗтимагый тикшереп торуны көчәйтү, тиешле өлкәдә ачыклык, законлылык һәм һөнәри осталык принципларын үстерү.

2.2. Иҗтимагый совет бурычлары түбәндәгеләр була:

архив эше өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү;

архив эшчәнлеге мәсьәләләренә кагылышлы норматив хокукый актлар проектларына иҗтимагый экспертиза уздыру, шул исәптән ТР Дәүләт архив комитеты тарафыннан әзерләнүче дәүләт программалары проектлары буенча фикер алышулар уздыру;

ТР Дәүләт архив комитеты тарафыннан карарлар кабул иткәндә иҗтимагый фикерне исәпкә алу механизмын камилләштерү;

ТР Дәүләт архив комитеты эшчәнлегенең төп юнәлешләре буенча җәмәгатьчелекне мәгълүмат белән тәэмин итүне арттыру;

«ТР ДА» ДБУ тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр сыйфатын бәйсез бәяләү (алга таба – сыйфатны бәйсез бәяләү) уздыру;

сыйфатны бәйсез бәяләү уздыру өчен мәгълүмат җыю.

2.3. Иҗтимагый совет максатлары һәм бурычлары, аның эш нәтиҗәләренә бәйле рәвештә, шулай ук Россия Федерациясендә икътисадый, социаль һәм сәяси вәзгыятьне исәпкә алып, үзгәртелергә һәм аларга өстәмәләр кертелергә мөмкин.

2.4. Иҗтимагый совет сыйфатны бәйсез бәяләүне гамәлгә ашырганда, үзенә йөкләнгән бурычлар чикләрендә, түбәндәгеләрне башкара:

үзләренә карата сыйфатны бәйсез бәяләү уздырыла торган оешмалар исемлеген билгели;

кирәк булганда «ТР ДА» ДБУ тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын бәйсез бәяләү критерийларын билгели;

ТР Дәүләт архив комитетына түбәндәгеләрне җибәрә:

сыйфатны бәйсез бәяләү нәтиҗәләрен;

оешмаларның тиешле эшчәнлеген яхшырту турында тәкъдимнәрне.

## 3. Иҗтимагый совет составы

3.1. Иҗтимагый совет Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланучы Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты һәм ведомствосы каршындагы иҗтимагый совет төзү тәртибе нигезендә формалаштырыла.

Иҗтимагый совет составында 17 кеше булган ирекле катнашу нигезендә, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы белән берлектә, ТР Дәүләт архив комитеты тарафыннан формалаштырыла.

3.2. ТР Дәүләт архив комитеты, Иҗтимагый совет составы расланган көннән 30 көннән дә соңга калмыйча, Иҗтимагый советның беренче утырышын уздыруны оештыра, анда аның әгъзалары арасыннан Иҗтимагый совет рәисе һәм рәисе урынбасары сайлана. Карар Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми саныннан күпчелек тавыш белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә.

3.3. Иҗтимагый совет рәисен яисә рәисе урынбасарын вазыйфасыннан азат итү турындагы мәсьәлә башкарма орган җитәкчесе мөрәҗәгате буенча, шулай ук Иҗтимагый совет рәисенең яисә рәисе урынбасарының шәхси гаризасы буенча яисә Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми саныннан кимендә биштән берен тәшкил итүче сандагы Иҗтимагый совет әгъзалары төркеме тәкъдиме буенча Иҗтимагый совет тарафыннан карала. Карар Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә.

3.4. Иҗтимагый совет рәисе Иҗтимагый совет әгъзалары арасыннан Иҗтимагый советның җаваплы секретарен билгеләп куя.

3.5. Иҗтимагый совет әгъзаларының вәкаләтләре срогы Иҗтимагый советның яңадан формалаштырылган составының беренче утырышы узган көннән соң өч ел тәшкил итә.

3.6. Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләре түбәндәге очракларда Иҗтимагый совет рәисе тәкъдиме буенча башкарма орган боерыгы нигезендә туктатып торыла:

аңа карата Россия Федерациясенең җинаять-процессуаль законнары белән билгеләнгән тәртиптә җинаять кылуда гаепләү белдерелгән;

аңа карата административ кулга алу рәвешендә административ җәза билгеләнгән;

аны дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органы депутатлыгына кандидат сыйфатында, җирле үзидарә органында сайлаулы вазыйфага кандидат сыйфатында, сәяси партия кандидатының ышанычлы заты яисә вәкаләтле вәкиле сыйфатында теркәгән, шулай ук ул Россия

Федерациясендә референдум уздыру буенча инициатив төркем составына кергән очракта.

3.7. Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләре түбәндәге очракларда туктатыла:

аның вәкаләтләре срогы тәмамланган;

ул Иҗтимагый совет составыннан чыгу турында гариза биргән;

ул сәламәтлеге торышы аркасында Иҗтимагый совет эшендә катнашырга сәләтсез булган;

аңа карата судның чыгарылган гаепләү карары закон көченә кергән;

закон көченә кергән суд карары нигезендә аны хокукка сәләтсез дип таныган яисә ул хәбәр итмичә килмәгән;

ул әхлак нормаларын дорфа рәвештә бозган – Иҗтимагый совет утырышында катнашучы әгъзалар санынннан күпчелек тавыш белән кабул ителгән Иҗтимагый совет карары буенча;

мәгълүм сәбәпләрсез Иҗтимагый совет утырышлары эшендә даими рәвештә (өч мәртәбәдән артык) катнашмаган;

мәгълүм сәбәпләрсез Иҗтимагый совет рәисенең яисә рәисе урынбасарының йөкләмәләрен даими рәвештә (ике мәртәбәдән артык) үтәмәгән;

ул Россия Федерациясе дәүләт вазыйфасына, Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең бүтән субъектлары дәүләт вазыйфасына, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең бүтән субъектлары дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына, муниципаль вазыйфага яисә муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләп куелган;

ул башка дәүләт гражданлыгын (ватандашлыгын) алган;

Россия Федерациясе гражданлыгын туктаткан.

3.8. Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләрен туктату Иҗтимагый совет әгъзасының язма гаризасы йә Иҗтимагый совет рәисе яисә рәисе урынбасары күрсәтүе буенча башкарма орган боерыгы нигезендә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 3.7 пункты белән каралган хәлләр ачыкланган очракта гамәлгә ашырыла.

Иҗтимагый совет әгъзасы әлеге Нигезләмәнең 3.7 пунктындагы дүртенче, бишенче, унынчы – уникенче абзацлары белән каралган хәлләр барлыкка килү турында Иҗтимагый совет рәисенә яисә рәисе урынбасарына хәбәр итәргә тиеш.

## 4. Иҗтимагый совет әгъзаларының хокуклары һәм бурычлары

4.1. Иҗтимагый совет әгъзасы түбәндәгеләргә хокуклы:

ТР Дәүләт архив комитеты инициативасы буенча уздырыла торган барлык чараларда (утырышларда, киңәшмәләрдә, «түгәрәк өстәлләрдә» һәм башкаларда катнашырга), дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләре, шәхси күрсәткечләр турындагы белешмәләре булган мәгълүматны һәм куллану

мөмкинлеге чикләнгән мәгълүматны файдалануга бәйле рәвештә федераль законнар нигезендә керү чикләнгән чаралардан гайре;

инициатив тәртиптә аналитик язмалар, нотыклар һәм башка мәгълүмат-аналитик материаллар әзерләргә һәм Иҗтимагый советка җибәрергә;

Иҗтимагый совет рәисе аша Иҗтимагый советның эш планына һәм аның утырышлары көн тәртибенә тәкъдимнәр кертергә;

көн тәртибендәге мәсьәләләрне карауда катнашу өчен Иҗтимагый совет утырышына чакырылучы затларның кандидатуралары буенча тәкъдимнәр кертергә;

Иҗтимагый совет әгъзалыгыннан чыгарга.

4.2. Иҗтимагый совет әгъзасының бурычлары түбәндәгеләр:

Иҗтимагый совет рәисе тарафыннан бирелгән йөкләмәләрне үтәргә;

Иҗтимагый совет эшенең әлеге Нигезләмә белән каралган тәртибен белергә һәм үтәргә;

Иҗтимагый совет утырышларында шәхсән катнашырга;

үзенә йөкләнгән бурычларны хәл итү өчен эксперт, эш төркемнәре, комиссияләр, Иҗтимагый совет тарафыннан төзелә торган бүтән эшче органнар эшендә катнашырга.

## 5. Иҗтимагый советның эш тәртибе

5.1. Иҗтимагый совет үз эшен Иҗтимагый совет рәисе күрсәтмәсе буенча Иҗтимагый совет утырышында раслана торган планнар һәм программалар нигезендә оештыра.

5.2. Иҗтимагый совет эшен планлаштыруны Иҗтимагый совет әгъзалары, Иҗтимагый совет рәисе һәм ТР Дәүләт архив комитеты тәкъдимнәре нигезендә гамәлгә ашыра.

5.3. Иҗтимагый совет утырышлары кимендә кварталга бер мәртәбә уздырыла. Иҗтимагый совет утырышларында кабул ителгән карарлар беркетмә белән рәсмиләштерелә.

Иҗтимагый совет утырышлары шулай ук «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан әзерләнә торган, башкарма хакимияте органнар каршындагы иҗтимагый советлар утырышларында фикер алышудан башка кабул ителә алмый торган норматив хокукый актлар һәм бүтән документлар составын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 29.03.2013 № 214 карары белән расланган Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан әзерләнә торган, башкарма хакимияте органнар каршындагы иҗтимагый советлар утырышларында фикер алышудан башка кабул ителә алмый торган норматив хокукый актлар һәм бүтән документлар исемлегендә каралган, ТР Дәүләт архив комитеты тарафыннан әзерләнгән норматив хокукый актлар проектларына Иҗтимагый совет бәяләмәсен бирү максатларында, ТР Дәүләт архив комитеты инициативасы буенча уздырыла.

5.4. Иҗтимагый совет утырышлары, әгәр аларда Иҗтимагый совет әгъзаларының кимендә өчтән икесе катнашса, тулы хокуклы дип санала.

Иҗтимагый совет әгъзасы шәхсән катнаша алмаган очракта, көн тәртибенә кертелгән мәсьәлә буенча үз тавышын һәм үз фикерен язма рәвештә, факсимиль яисә электрон почта аша Иҗтимагый советның бүтән әгъзасына тапшырырга хокуклы, ул бу хакта Иҗтимагый совет рәисенә, яисә рәисе урынбасарына, яисә Иҗтимагый совет секретарена алдан хәбәр итәргә тиеш. Иҗтимагый совет утырышында катнашучы әгъзалар санына үз тавышларын Иҗтимагый советның бүтән әгъзаларына ышанып тапшырган Иҗтимагый совет әгъзалары да өстәлә.

Иҗтимагый совет тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 5.3 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән норматив хокукый актлар проектларын (норматив хокукый актларны) карау аларны ТР Дәүләт архив комитеты тарафыннан Иҗтимагый советка җибәргән көннән ун календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла. Бу чакта Иҗтимагый совет бәяләмәләрен бирү максатларында алар буенча тавыш бирүне уздыру читтән торып, Иҗтимагый советның барлык әгъзаларын сораштыру рәвешендә гамәлгә ашырылырга мөмкин, сораштыру нәтиҗәләре Иҗтимагый совет рәисе тарафыннан имзалана торган, ә ул булмаганда – Иҗтимагый совет рәисе урынбасары тарафыннан имзалана торган беркетмәгә кертелә. Мондый тавыш бирү почта, телеграф, телетайп аша, телефон, электрон рәвештә яисә тапшырыла торган һәм кабул ителә торган хәбәрләрнең хакыйкый булуын һәм аларның документаль расланышын тәэмин итәрлек бүтән төр элемтә чаралары аша документлар алмашу юлы белән уздырылырга мөмкин. Читтән торып тавыш бирү уздырган очракта, Иҗтимагый совет рәисенең урынбасарына, барлык әгъзаларына тәкъдим ителүче көн тәртибе, Иҗтимагый совет тарафыннан бәяләмә бирелергә тиешле норматив хокукый акт проекты (норматив хокукый акт) Иҗтимагый совет утырышын уздыру датасына кадәр җиде календарь көннән дә соңга калмыйча җибәрелә. Иҗтимагый совет әгъзалары кирәк чакта карала торган норматив хокукый акт проекты (норматив хокукый акт) буенча ТР Дәүләт архив комитетыннан өстәмә материаллар һәм мәгълүмат соратып алалар.

Иҗтимагый совет карарлары гади күпчелек тавыш белән кабул ителә.

5.5. Иҗтимагый совет утырышларын Иҗтимагый совет рәисе уздыра, ә ул булмаган очракта – Иҗтимагый совет рәисе урынбасары.

5.6. Иҗтимагый советның аңа йөкләнгән максатлар, бурычлар, вәкаләтләр нигезендә кабул ителә торган карарлары тәкъдим итү характерында була һәм кызыксынучы затларга Иҗтимагый совет утырышы беркетмәсеннән өземтә рәвешендә йә Иҗтимагый совет карары буенча бүтән ысул белән җиткерелә.

5.7. Иҗтимагый совет эшчәнлеге турындагы мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты» сайтындагы «Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты каршындагы Иҗтимагый совет» бүлегендә урнаштырыла.

5.8. Иҗтимагый совет рәисе:

Иҗтимагый совет эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итә;

Иҗтимагый совет утырышын алып бара;

Иҗтимагый совет әгъзалары тәкъдимнәре нигезендә Иҗтимагый совет эше планнарын әзерли, шулай ук аларга үзгәрешләр кертә һәм аларны Иҗтимагый совет раславына тәкъдим итә;

Иҗтимагый совет утырышын оештыра;

Иҗтимагый совет утырышының көн тәртибен раслый;

Иҗтимагый совет рекомендацияләренә, беркетмәләренә һәм Иҗтимагый советның бүтән документларына имза сала;

Иҗтимагый совет утырышларын уздыру вакытын һәм урынын билгели;

Иҗтимагый совет эшчәнлеге, аңа йөкләнгән максатлар һәм бурычлар кысаларында Иҗтимагый совет әгъзаларына йөкләмәләр бирә;

гарызнамәләргә, рекомендацияләргә, тәкъдимнәргә, җавапларга, аңлатуларга һәм мөрәҗәгатьләргә Иҗтимагый совет исеменнән имза сала;

Иҗтимагый совет эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле бүтән функцияләрне гамәлгә ашыра.

5.9. Иҗтимагый совет рәисе урынбасары:

Иҗтимагый совет рәисе рәсми рәвештә булмаган вакытта аның функцияләрен үти;

Иҗтимагый совет утырышларын әзерләүне оештыра;

Иҗтимагый совет утырышлары көн тәртибен төзи һәм аны Иҗтимагый совет рәисе раславына тәкъдим итә;

Иҗтимагый совет рәисе кушуы буенча Иҗтимагый совет эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле бүтән функцияләрне гамәлгә ашыра.

5.10. Иҗтимагый советның җаваплы секретаре:

утырышларга материаллар һәм карарлар проектларын әзерләүне оештыра;

Иҗтимагый совет әгъзаларына Иҗтимагый совет утырышын уздыру вакыты һәм урыны, көн тәртибе турында хәбәр итә, аларны кирәкле мәгълүмат-белешмә материаллары белән тәэмин итә;

Иҗтимагый советның һәм башкарма органның оештыру хезмәттәшлеген тәэмин итә;

Иҗтимагый совет эшчәнлеген документаль-техник тәэмин итүне гамәлгә ашыра;

Иҗтимагый совет утырышлары беркетмәләрен рәсмиләштерә һәм кабул ителгән карарларны тикшереп торуны гамәлгә ашыра;

Иҗтимагый совет утырышлары көн тәртибен төзүдә катнаша.

5.11. Иҗтимагый совет әгъзалары Иҗтимагый совет утырышларында тыңлауга һәм фикер алышуга чыгарыла торган мәсьәләләрне әзерләү өчен эш, эксперт төркемнәренә һәм бүтән эш органнарына берләшергә, Иҗтимагый совет составына кермәүче белгечләрне Иҗтимагый совет рәисе урынбасары белән килештерү буенча материаллар әзерләүгә җәлеп итәргә мөмкин.

5.12. Иҗтимагый совет карары буенча Иҗтимагый совет утырышларына башкарма хакимият органнары, коммерциячел булмаган оешмалар, фәнни учреждениеләр вәкилләре, экспертлар һәм кирәкле белешмәләр һәм

Иҗтимагый совет тарафыннан карала торган мәсьәләләр буенча бәяләмәләр бирү өчен башка белгечләр дә чакырылырга мөмкин. Иҗтимагый совет әгъзалары булмаган массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре Иҗтимагый совет утырышларында Иҗтимагый совет чакыруы буенча катнашырга мөмкин.

Иҗтимагый совет аның эшендә Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзалары катнашуны тәэмин итә.

5.13. Иҗтимагый совет каравына кертелә торган материаллар, Иҗтимагый советның әлеге мәсьәләләрне карау күз алдында тотыла торган утырышын уздыру датасы билгеләнгәнгә кадәр ун календарь көннән дә соңга калмыйча, Иҗтимагый совет рәисе урынбасарына тапшырылырга тиеш. Материалларны соңрак срокларда тапшыру Иҗтимагый совет рәисе яисә рәисе урынбасары белән килештерелә.

5.14. Иҗтимагый совет эшчәнлеген техник һәм оештыру ягыннан тәэмин итү ТР Дәүләт архив комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

______________________________